Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының чираттан тыш утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

20 июль, 2020 ел № 80

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлеше турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында һәм «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 17 апрелендәге 631 номерлы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертларны «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 пункты нигезендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 3 пункты белән җибәрергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н.Саттарова